ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2024 г.Казань № 487-29/тко-2024

2025-2027 елларга Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция һәм җитештерү программаларын эшләү, раслау һәм төгәлләштерү тәртибен, шул исәптән эшкәртү, йогышсызландыру, күмү объектларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлы һәм факттагы күрсәткечләрен билгеләү, шулай ук инвестиция һәм җитештерү программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 424 номерлы, «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя куюю турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карарлары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.12.2024 ел, № 32-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

әлеге карарның 1-2 нче кушымталары нигезендә Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә календар буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар;

Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, 2025-2027 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары.

2. Әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү программасын расларга.

3. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улына ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 487-29/тко-2024
карарына 1 нче кушымта

## Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2025 елга календарь буенча бүленгән чик тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/тонна | |
|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Кайбыч муниципаль районы | | |
| 1 | Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы* | 1 559,19 | 1 738,32 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана, Россия Федерациясе Салым кодексының 145 статьясы нигезендә өстәлгән бәягә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүче вазыйфаларын башкарудан азат ителә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 487-29/тко-2024
карарына 2 нче кушымта

Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2026 – 2027* елларга календарь буенча бүленгән чик тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/тонна | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2026 ел | | 2027 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Кайбыч муниципаль районы | | | | |
| 1 | Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы** | 1 738,32 | 2 266,83 | 2 054,81 | 2 054,81 |

<*> 2026-2027 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы чик дәрәҗә тарифларны ел саен төгәлләштерү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя куюу турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары һәм Монополиягә каршы хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана, Россия Федерациясе Салым кодексының 145 статьясы нигезендә өстәлгән бәягә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле салым түләүче вазыйфаларын башкарудан азат ителә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 487-29/тко-2024
карарына 3 нче кушымта

Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2025-2027 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары.

| № п/п | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе* | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре: Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2025 | 8 325,24 | х | 0,00 | 0,06 |
| | | 2026 | х | 1,00 | 0,00 | 0,06 |
| | | 2027 | х | 1,00 | 0,00 | 0,06 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 487-29/тко-2024
карарына 4 нче кушымта

| Оешманың җитештерү программасы | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты** | | | | |
| **Җайга салынулы оешма** | Кайбыч муниципаль районы шәхси эшкуары Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы | | | |
| Урнашкан урыны | 422330, Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Үзәк урам, 145 | | | |
| **Җайга салуның вәкаләтле органы** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | |
| Урнашкан урыны | 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2025 | тәмамлана | 31.12.2025 |

**2 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру исемлеге**

| № | Аталышы | Үлчәү берәмлеге | Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** |
| 1 | Объектларны агымдагы ремонтлау | мең сум | 8 490,67 | 10 313,39 | 10 582,29 |
| 2 | Агымдагы ремонт | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3 | Капиталь ремонт | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

**3 нче бүлек. Күмелә торган каты коммуналь калдыкларның планлаштырылган массасы**

| № | Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** |
| 1 | Каты коммуналь калдыкларның массасы | мең тонна | 39,73 | 39,73 | 39,73 |

**4 нче бүлек. Финанс ихтыяҗлары күләме**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткеч зурлыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2025 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** |
| 1 | Җитештерү чыгымнары | мең сум | 7 768,81 | 8 022,57 | 8 260,32 |
| 1.1 | Материаллар һәм азкыйммәтле төп чаралар | мең сум | 1 950,82 | 2 014,36 | 2 073,98 |
| 1.2 | Электр энергиясенә чыгымнар | мең сум | 24,09 | 25,60 | 26,65 |
| 1.3 | Каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, зарарсызландыру, күмү өчен файдаланыла торган объектлардан эксплуатацияләүгә бәйле чит оешмалар яисә шәхси эшкуарлар тарафыннан башкарыла торган эшләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 1.4 | Төп җитештерү персоналының хезмәте өчен түләү һәм социаль ихтыяҗларга чигерү чыгымнары, шул исәптән салымнар һәм җыемнар | мең сум | 4 773,36 | 4 928,83 | 5 074,72 |

<table>
<tr><td>1.5</td><td>гомумхуҗалык чыгымнары</td><td>мең сум</td><td>1 020,54</td><td>1 053,78</td><td>1 084,97</td></tr>
<tr><td>1.6</td><td>Башка төр җитештерү чыгымнары</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Каты коммуналь калдыкларны урнаштырганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү чыгымнары</td><td>мең сум</td><td>489,23</td><td>489,23</td><td>489,23</td></tr>
<tr><td>3</td><td>Ремонт чыгымнары</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>4</td><td>Административ чыгымнар</td><td>мең сум</td><td>599,77</td><td>619,30</td><td>637,64</td></tr>
<tr><td>5</td><td>Саты чыгымнары (шикле бурычлар)</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>6</td><td>Амортизация</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>7</td><td>Аренда түләвенә, лизинг түләүләренә, концессия түләвенә чыгымнар</td><td>мең сум</td><td>160,58</td><td>160,58</td><td>160,58</td></tr>
<tr><td>8</td><td>Салымнар һәм җыемнар түләүгә бәйле чыгымнар</td><td>мең сум</td><td>548,44</td><td>556,34</td><td>556,34</td></tr>
<tr><td>9</td><td>Эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы башка оешмалардан сатып алына торган товарлар (хезмәт күрсәтүләр, эшләр) өчен түләү чыгымнары</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>10</td><td>Башка төр контрольлектә булмаган чыгымнар</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>11</td><td>Алынмаган керемнәр / Төшеп кала торган чыгымнар</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>12</td><td>Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар</td><td>мең сум</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>13</td><td>Җайга салуның узган чорларының икътисадый яктан нигезләнмәгән керемнәре</td><td>мең сум</td><td>1 554,50</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>14</td><td>Исәпләнгән эшкуарлык табышы</td><td>мең сум</td><td>478,34</td><td>465,37</td><td>478,18</td></tr>
<tr><td>15</td><td>Кирәкле тулай табыш</td><td>мең сум</td><td>8 490,67</td><td>10 313,39</td><td>10 582,29</td></tr>
<tr><td colspan="6">5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы</td></tr>
<tr><td>№</td><td>Чараның аталышы</td><td colspan="4">план чоры</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="5">Җитештерү программасын гамәлгә ашыру кысаларындагы чаралар каралмаган.</td></tr>
<tr><td colspan="6">6 нчы бүлек. Объектларның нәтиҗәлелек күрсәткечләренең план һәм факт күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2">Күрсәткеч</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="3">Күрсәткеч зурлыгы</td></tr>
<tr><td>2025 ел</td><td>2026 ел</td><td>2027 ел</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Эшчәнлек башкаруга экологик тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлап алынган җир асты сулары, туфрак һәм һава пробаларының гомуми өлешендә мондый пробаларның билгеләнгән таләпләргә туры килми торган өлеше</td><td>%</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Каты коммуналь калдыкларны күмү объекты мәйданы берәмлеге исәбеннән каты коммуналь калдыкларның япып китү очраклары саны</td><td>%</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td colspan="6">7 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап</td></tr>
<tr><td colspan="6">Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап оешманың 2023 елга финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисабы составында бирелде.</td></tr>
</table>